КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 24 ноябрь г.Казань № 900

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кеше һәм табигать» һәм «ЭКОлидер» еллык республика конкурсларын үткәрү турында» 2004 ел, 28 июнь, 307 нче карарына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кеше һәм табигать» һәм «ЭКОлидер» еллык республика конкурсларын үткәрү турында» 2004 ел, 28 июнь, 307 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 27 июнь, 256 нчы; 2010 ел, 9 март, 124 нче; 2010 ел, 24 март, 191 нче; 2013 ел, 27 август, 601 нче; 2014 ел, 30 сентябрь, 697 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ЭКОлидер» еллык республика конкурсын үткәрү турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә табигатьтән рациональ файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлек мәсьәләләрен нәтиҗәле хәл итүне тәэмин итүче оешмаларны, индивидуаль эшмәкәрләрне, җирле үзидарә органнарын, мәгариф оешмаларын, иҗтимагый берләшмәләрне, гражданнарны, журналистларны бүләкләү һәм стимуллаштыру максатыннан чыгып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 – 3 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының «ЭКОлидер» еллык республика конкурсын үткәрү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Бу каррарга теркәлгән «ЭКОлидер» еллык республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәне (алга таба – Конкурс турындагы нигезләмә) расларга.

3. Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына, Конкурс турындагы нигезләмәгә таянып, «ЭКОлидер» еллык республика конкурсын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.»;

4 нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ЭКОлидер» еллык республика конкурсы кысаларында үткәрелә торган чараларны финанслауны тиешле елга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 28 декабрь, 1083 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына күздә тотылган акча исәбеннән түбәндәгеләрне үз эченә алган чыгымнар сметасына нигезендә гамәлгә ашыруны:»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ЭКОлидер» еллык республика конкурсының бүләкләү фондын 640,0 мең сум күләмендә билгеләргә.»;

5 нче пунктта «Кеше һәм табигать» һәм «ЭКОлидер» еллык республика конкурсларында һәм» дигән сүзләрне «ЭКОлидер» еллык республика конкурсында» дигән сүзләргә алыштырырга;

7 нче пунктта «конкурсларда» дигән сүзне «ЭКОлидер» еллык республика конкурсында» дигән сүзләргә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган «ЭКОлидер» еллык республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәне бу карарга теркәлгән кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел саен үткәрелә торган «Кеше һәм табигать» һәм «ЭКОлидер» республика конкурсларын уздыру турында» 2004 ел, 28 июнь, 307 нче карары белән расланган Ел саен үткәрелә торган «ЭКОлидер» республика конкурсын уздыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 24 март, 191 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кеше һәм табигать» һәм «ЭКОлидер» еллык республика конкурсларын үткәрү турында» 2004 ел, 28 июнь, 307 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 ел, 27 август, 601 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кеше һәм табигать» һәм «ЭКОлидер» еллык республика конкурсларын үткәрү турында» 2004 ел, 28 июнь, 307 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 30 сентябрь, 697 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2004 ел, 28 июнь, 307 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 24 ноябрь, 900 нче
карары редакциясендә)

«ЭКОлидер» еллык республика конкурсын үткәрү турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә «ЭКОлидер» еллык республика конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү максатын, бурычларын, тәртибен билгели.

1.2. Конкурсны үткәрү максаты – Татарстан Республикасы территориясендә табигатьтән рациональ файдалану, экология белеме бирү һәм мәгърифәт, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлек мәсьәләләрен нәтиҗәле хәл итүне тәэмин итүче сәнәгать һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге оешмаларны һәм индивидуаль эшмәкәрләрне, җирле үзидарә органнарын, иҗтимагый берләшмәләрне, мәгариф оешмаларын, гражданнарны, массакүләм мәгълүмат чараларын бүләкләү һәм стимуллаштыру.

1.3. Конкурс ел саен бу Нигезләмәнең 3.1 нче пункты белән күздә тотылган конкурс төркемнәре һәм номинацияләр буенча үткәрелә. Һәр номинациядә I, II, III урыннарын бирү күздә тотыла.

1.4. Конкурста катнашу өчен гаризалар эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы һәм табигатьтән рациональ файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлек мәсьәләләрен нәтиҗәле хәл итүне тәэмин итүче сәнәгать һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге оешмалардан һәм индивидуаль эшмәкәрләрдән, җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән, мәгариф оешмаларыннан, гражданнардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан кабул ителә.

1.5. Конкурсны оештыру һәм үткәрү Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.6. Конкурсны үткәрү вакытлары, шартлары һәм аның нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат Министрлыкның «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составындагы рәсми сайтында урнаштырыла.

1.7. Конкурсны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 28 декабрь, 1083 нче

карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасы кысаларында гамәлгә ашырыла.

## 2. Конкурсның бурычлары

2.1. Конкурсның бурычлары – түбәндәгеләр:

дәүләт экология сәясәтенең төп юнәлешләрен тормышка ашыру; Җир Хартиясенең төп принципларын популярлаштыру;

Татарстан Республикасында экология хәрәкәтен үстерү;

табигатьтән рациональ файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлек мәсьәләләрен хәл итүдә иң яхшы нәтиҗәләргә ирешкән оешмаларны, индивидуаль эшмәкәрләрне, җирле үзидарә органнарын, иҗтимагый берләшмәләрне, гражданнарны, массакүләм мәгълүмат чараларын ачыклау;

экология белеме бирү системасын үстерү һәм экология культурасын формалаштыру;

экология өлкәсендә үсеп килүче буын эшчәнлеген үстерү;

үсеп килүче буынның туган як табигатен өйрәнүгә һәм аның экологик торышын бәяләүгә юнәлдерелгән тикшеренү эшчәнлеген камилләштерү;

әйләнә-тирә мохитне саклау турындагы белемнәрне пропагандалау һәм халыкта аңа карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү;

гражданнарның әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләренә карата актив позициясен формалаштыру.

## 3. Конкурс төркемнәре һәм номинацияләр

3.1. Конкурс түбәндәге конкурс төркемнәрендә һәм номинацияләр буенча үткәрелә:

| Конкурс төркеме | Номинация |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Сәнәгать һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә оешмалар һәм индивидуаль эшмәкәрләр | нефть һәм газ сәнәгате;<br>энергетика;<br>төзелеш сәнәгате;<br>агросәнәгать һәм урман сәнәгате;<br>торак-коммуналь комплекс |
| Белем бирү оешмалары | мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында экология белеме бирү;<br>гомуми белем бирү оешмаларында экология белеме бирү;<br>югары белем бирүче мәгариф оешмаларында һәм өстәмә белем бирүче оешмаларда экология белеме бирү |

| | |
|---|---|
| Җирле үзидарә органнары | Татарстан Республикасы муниципаль районы территориясендә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге казанышы өчен;<br>Татарстан Республикасы шәһәрләре территориясендә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге казанышы өчен;<br>Татарстан Республикасы авыл җирлекләре территориясендә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге казанышы өчен |
| Иҗтимагый оешмалар һәм гражданнар | иҗтимагый оешмалар;<br>гражданнар;<br>халык контроле |
| Массакүләм мәгълүмат чаралары | иң яхшы телесюжет;<br>иң яхшы радиосюжет;<br>электрон массакүләм мәгълүмат чараларының иң яхшы материалы;<br>матбугат басмаларында чыккан иң яхшы материал |

4. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

4.1. Конкурста катнашу өчен гариза бирүчеләр агымдагы елның 1 сентябреннән 15 ноябренә кадәр түбәндәгеләрне материалларны кертә:

Бу Нигезләмәгә теркәлгән 1 – 5 нче кушымталарда күрсәтелгән форма буенча Конкурста катнашучының мәгълүмат картасын;

Бу Нигезләмәгә теркәлгән 6 нчы кушымтада күрсәтелгән форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга ризалыкны;

экологик проектларны һәм программаларны (булганда);

фотоматериалларны (видеоматериалларны);

Татарстан Республикасы территориясендә табигатьтән рациональ файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлек өлкәсендә башкарыла торган эшләрнең тасвирламасын;

басылып чыккан мәгълүмат, нәшрият органы исемен, басылып чыгу көнен күрсәтеп, авторы (авторлары) һәм нәшрият органы турындагы белешмәләр белән басма материалларны;

материал, тапшыру исемен, эфирга чыгу көнен күрсәтеп, авторы (авторлары) һәм теле- һәм радиоканал турындагы белешмәләр белән видео- һәм аудиофайлларны;

исемен күрсәтеп, фотосурәт эшләрен.

4.2. Конкурска кертелгән материалларны бәяләү өчен төп критерийлар булып түбәндәгеләр тора:

табигатьтән рациональ файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлек өлкәсендә бурычларны һәм проблемаларны хәл итүгә карата тормышка ашырыла торган юллар һәм комплекслылык;

табигатьтән рациональ файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлек өлкәсендәге бурычларны һәм проблемаларны хәл итүгә инновацион якын килү;

идеяләрнең оригинальлеге;

идеянең үзенчәлеклелеге;

Конкурста катнашучы куллана торган хәл итү юлларын гамәлгә кертү нәтиҗәләрен тасвирлау аңлаешлы булу;

иҗтимагый инициатива һәм социаль эффект;

гражданнарның экологик культурасын арттыру һәм экологик аң-белем бирү өлкәсендә материалларның актуальлеге;

медиасы ягыннан җәлеп итүчәнлек, бирү яңалыгы һәм мәгълүмати яктыртуның җитезлеге;

нәтиҗәлелек (нәтиҗәләрнең куелган бурычларга туры килүе, экологик проектларны һәм программаларны тормышка ашыруның сан һәм сыйфат күрсәткечләре).

4.3. Бу Нигезләмәнең 4.1 нче пункты белән күздә тотылган материаллар Министрлыкка 420049, Казан шәһәре, Павлюхин урамы, 75 нче йорт адресы буенча «ЭКОлидер» конкурсы» тамгасы белән йомышчы, почта аша яки электрон почта белән җибәрелә, белешмәләр өчен телефон: 8 (843) 267-68-11 (экологик аң-белем бирү һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итү бүлеге).

4.4. Конкурста катнашу өчен җибәрелгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

4.5. Материалларны кабул итеп бетергәннән һәм аларны эшкәрткәннән (тулылыгын тикшергәннән, тәгаенләгәннән) соң җиде календарь көн эчендә кабул ителгән материаллар конкурс комиссиясенә карауга кертелә.

4.6. Бу Нигезләмәнең 4.2 нче пункты белән билгеләнгән материалларны бәяләү критерийлары нигезендә конкурс комиссиясе 14 календарь көн эчендә җибәрелгән эшләрне бәяли һәм Конкурста җиңүчеләрне билгели.

## 5. Конкурс комиссиясе

5.1. Конкурс комиссиясе составы Министрлык тарафыннан раслана. Конкурс комиссиясе составына Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары вәкилләре, галимнәр, иҗтимагый экологик берләшмәләр вәкилләре керә.

5.2. Конкурс комиссиясе эше, әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, утырышлар рәвешендә үткәрелә.

5.3. Конкурс комиссиясе эше белән аның рәисе җитәкчелек итә. Конкурс комиссиясе рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

5.4. Конкурс комиссиясе карары утырышта катнашучы конкурс комиссиясе әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә.

5.5. Тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе рәисе яки аны алыштыручы зат тавышы хәлиткеч тавыш булып санала.

5.6. Конкурс комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа конкурс комиссиясе рәисе яки аны алыштыручы зат һәм әгъзалары кул куя.

5.7. Конкурс комиссиясе сәркатибе конкурс комиссиясе әгъзалары составына керми һәм аның утырышларында тавыш бирү хокукыннан башка катнаша.

## 6. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү

6.1. Конкурста җиңүчеләр «Сәнәгать һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә оешмалар һәм индивидуаль эшмәкәрләр», «Белем бирү оешмалары», «Җирле үзидарә органнары» конкурс төркемнәрендә диплом һәм кубок белән бүләкләнә.

Конкурс комиссиясе карары буенча бу Нигезләмәнең 5.4 нче пункты нигезендә «Сәнәгать һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә оешмалар һәм индивидуаль эшмәкәрләр» конкурс төркемендә Конкурста катнашучыга өстәмә рәвештә «Абсолют җиңүче» исеме бирелә, диплом һәм кубок тапшырыла.

6.2. «Иҗтимагый берләшмәләр һәм гражданнар» конкурс төркемендә Конкурста җиңүчеләр түбәндәге күләмнәрдәге акчалата бүләкләр белән бүләкләнә:

| Урын | Номинацияләр | | |
|---|---|---|---|
| | «Иҗтимагый оешмалар» | «Гражданнар» | «Халык контроле» |
| I | 40,0 мең сум | 15,0 мең сум | 15,0 мең сум |
| II | 30,0 мең сум | 10,0 мең сум | 10,0 мең сум |
| III | 20,0 мең сум | 5,0 мең сум | 5,0 мең сум |

6.3. «Массакүләм мәгълүмат чаралары» конкурс төркемендә «Иң яхшы телесюжет» номинациясендә Конкурста җиңүчеләр түбәндәге күләмнәрдәге акчалата бүләкләр белән бүләкләнә:

| Урын | I ярдәмче төркем – республика массакүләм мәгълүмат чаралары | II ярдәмче төркем – шәһәрләр һәм районнарның массакүләм мәгълүмат чаралары |
|---|---|---|
| I | 30,0 мең сум | 30,0 мең сум |
| II | 20,0 мең сум | 20,0 мең сум |
| III | 15,0 мең сум | 15,0 мең сум |

6.4. «Массакүләм мәгълүмат чаралары» конкурс төркемендә «Иң яхшы радиосюжет» номинациясендә Конкурста җиңүчеләр түбәндәге күләмнәрдәге акчалата бүләкләр белән бүләкләнә:

| Урын | I ярдәмче төркем – республика массакүләм мәгълүмат чаралары | II ярдәмче төркем – шәһәрләр һәм районнарның массакүләм мәгълүмат чаралары |
|---|---|---|
| I | 20,0 мең сум | 20,0 мең сум |
| II | 15,0 мең сум | 15,0 мең сум |

| | | |
|---|---|---|
| III | 10,0 мең сум | 10,0 мең сум |

6.5. «Массакүләм мәгълүмат чаралары» конкурс төркемендә «Электрон массакүләм мәгълүмат чараларының иң яхшы материалы» номинациясендә Конкурста җиңүчеләр түбәндәге күләмнәрдәге акчалата бүләкләр белән бүләкләнә:

| Урын | I ярдәмче төркем – республика массакүләм мәгълүмат чаралары | II ярдәмче төркем – шәһәрләр һәм районнарның массакүләм мәгълүмат чаралары |
|---|---|---|
| I | 20,0 мең сум | 20,0 мең сум |
| II | 15,0 мең сум | 15,0 мең сум |
| III | 10,0 мең сум | 10,0 мең сум |

6.6. «Массакүләм мәгълүмат чаралары» конкурс төркемендә «Матбугат басмаларында чыккан иң яхшы материал» номинациясендә Конкурста җиңүчеләр түбәндәге күләмнәрдәге акчалата бүләкләр белән бүләкләнә:

| Урын | I ярдәмче төркем – республика массакүләм мәгълүмат чаралары | | II ярдәмче төркем – шәһәрләр һәм районнарның массакүләм мәгълүмат чаралары | |
|---|---|---|---|---|
| | татар телендә | рус телендә | татар телендә | рус телендә |
| I | 20,0 мең сум | 20,0 мең сум | 20,0 мең сум | 20,0 мең сум |
| II | 15,0 мең сум | 15,0 мең сум | 15,0 мең сум | 15,0 мең сум |
| III | 10,0 мең сум | 10,0 мең сум | 10,0 мең сум | 10,0 мең сум |

______________________

«ЭКОлидер» еллык республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта

Форма

**«Сәнәгать һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә оешмалар һәм индивидуаль эшмәкәрләр»**

конкурс төркемендә «ЭКОлидер» еллык республика конкурсында катнашучының мәгълүмат картасы

1. Номинация:
______________________________________________________________
2. Оешманың тулы исеме:_________________________________________
______________________________________________________________
3. Адресы: Татарстан Республикасы муниципаль районы: _________________
торак пункт: _________ урам: _________________________________ йорт _____
4. Оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының (булганда) исеме:
______________________________________________________________
4. Элемтә өчен мәгълүмат:
Җаваплы затның фамилиясе, исеме, атасының (булганда) исеме:
______________________________________________________________
Вазыйфасы: ____________________________________________________
Код белән эш телефоны: _________________________________________
Кәрәзле телефон: _______________________________________________
E-mail: _______________________________________________________
6. Эшчәнлек күрсәткечләре:

| Т/с | Күрсәткечнең исеме, үлчәү берәмлекләре | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Җитештерү күләмнәре, млн. сум | | | | | |
| 2. | Эшләүчеләрнең еллык уртача саны, кеше | | | | | |
| 3. | Ресурсларны саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау программасы | гамәлдә булган чор | | | | |
| 4. | Концентрацияләрнең рөхсәт ителгән иң чик күләмнәрен, чүп-чар чыгаруның рөхсәт ителгән иң чик күләмнәрен, пычраткыч матдәләр агызуның рөхсәт ителгән иң чик күләмнәрен, калдыклар | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | барлыкка килү лимитларын арттырып җибәрүнең билгеләнгән күләмнәре | | | | | |
| 5. | Су куллану күләмнәре, мең куб.метр, шул исәптән: | | | | | |
| 5.1. | җир өсте чыганагыннан | | | | | |
| 5.2. | җир асты чыганагыннан | | | | | |
| 6. | Су чыгару, мең куб метр, шул исәптән: | | | | | |
| 6.1. | җир өстендәге су объектларына | | | | | |
| 6.2. | чистартмыйча | | | | | |
| 6.3. | җитәрлек дәрәҗәдә чистартылган агынты сулар | | | | | |
| 6.4. | норматив буенча чиста сулар (чистартмыйча) | | | | | |
| 7. | Әйләнештәге су белән тәэмин итү, мең куб.метр | | | | | |
| 8. | Дәүләт статистика хисаплылыгы мәгълүматлары буенча чыгарылган пычраткыч матдәләр массасы, № 2-тп (су хуҗалыгы) формасы буенча, мең тонна | | | | | |
| 9. | Атмосферага пычраткыч матдәләр чыгару динамикасы, мең тонна, шул исәптән: | | | | | |
| 9.1. | барлыкка килде | | | | | |
| 9.2. | җыеп алынды һәм зарарсызландырылды | | | | | |
| 10. | Калдыклар барлыкка килү динамикасы, мең тонна: | | | | | |
| 10.1 | барлыкка килде | | | | | |
| 10.2 | үз җитештерүендә эшкәртелде | | | | | |
| 10.3 | эшкәртүгә бирелде | | | | | |
| 10.4 | күмү өчен җибәрелде | | | | | |
| 11. | Кулланышка кертелгән җиһазлар һәм технологияләр, саны шул исәптән: | | | | | |
| 11.1 | икенчел ресурслар җыю һәм эшкәртү буенча | | | | | |
| 11.2 | сәнәгать калдыклары барлыкка килү күләмнәрен киметүгә ярдәм итә торган технологияләр | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 11.3 | газларны чистарту җайланмалары | | | | | |
| 11.4 | газ ягулыгына күчерелгән автотранспорт | | | | | |
| 11.5 | сәнәгать агынты суларын чистарту технологияләре | | | | | |
| 11.6 | башкасы | | | | | |
| 12. | Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметүгә һәм ресурсларны сакчыл тотуга ярдәм итә торган технологияләр һәм җиһазлар кертүнең нәтиҗәләлеге: | | | | | |
| 12.1 | чыгаруны киметү, тонна | | | | | |
| 12.2 | агызуларны киметү, тонна | | | | | |
| 12.3 | калдыклар барлыкка килүне киметү, тонна | | | | | |
| 13. | Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экология иминлеге программасын һәм чараларын финанслау, мең сум, шул исәптән түбәндәгеләр буенча: | | | | | |
| 13.1 | су ресурсларын саклау һәм алардан рациональ файдалану | | | | | |
| 13.2 | атмосфера һавасын саклау | | | | | |
| 13.3 | калдыкларны утильләштерү һәм эшкәртү | | | | | |
| 13.4 | башкасы | | | | | |
| 14. | Оешма территориясен яшелләндерү, гомуми мәйданнан процент | | | | | |
| 15. | Техноген һәлакәтләр, саны | | | | | |
| 16. | Табигатьтән файдалануның икътисадый механизмын саклау һәм экология түләүләрен үз вакытында кертү, мең сум | | | | | |

М.У. (булганда) (имза) (оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының (булганда) исеме)

(датасы)

«ЭКОлидер» еллык республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта

Форма

**«Җирле үзидарә органнары»**
конкурс төркемендә «ЭКОлидер» еллык республика конкурсында катнашучының мәгълүмат картасы

1. Номинация:
________________________________________________________________
2. Җирле үзидарә органының тулы исеме:____________________________________
________________________________________________________________
3. Адресы: Татарстан Республикасы муниципаль районы: ______________________
торак пункт: _________ урам: _________________________________ _______йорт
4. Җирле үзидарә органы җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының (булганда) исеме: ______________________________________________________________
4. Элемтә өчен мәгълүмат:
Җаваплы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме:
________________________________________________________________
Вазыйфасы: ________________________________________________________
Код белән эш телефоны: ______________________________________________
Кәрәзле телефон: ___________________________________________________
E-mail: ____________________________________________________________
6. Эшчәнлек күрсәткечләре:

| Күрсәткеч исеме | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Шәһәр округлары һәм муниципаль районнар территориясендә табигатьне саклау чаралары программасы булу-булмау | гамәлдә булган чор | | | | |
| Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен җирле бюджетка күчерелгән түләүнең табигатьне саклау чараларын тормышка ашыруга тотылган суммага карата чагыштырмасы, процент | | | | | |

____________________________________________ ___/_______________________________/__
М.У. (булганда) (имза) (оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының (булганда) исеме)

_______________
(датасы)

«ЭКОлидер» еллык республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә 3 нче кушымта

Форма

**«Иҗтимагый берләшмәләр һәм гражданнар»**

конкурс төркемендә «ЭКОлидер» еллык республика конкурсында катнашучының мәгълүмат картасы

1. Номинация: ____________________________________________________________
2. Оешманың тулы исеме/Гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (тулысынча):_______________________________________________________________
3. Адресы: Татарстан Республикасы муниципаль районы: _______________________
торак пункт: _________ урам: ________________________________ йорт: ________
корпус: __________ фатир: ______________________________________________
4. Оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының (булганда) исеме: __________
_________________________________________________________________________
5. Элемтә өчен мәгълүмат:
Җаваплы затның фамилиясе, исеме, атасының (булганда) исеме:
_________________________________________________________________________
Вазыйфасы: _______________________________________________________________
Код белән эш телефоны: ____________________________________________________
Кәрәзле телефон: __________________________________________________________
E-mail: ___________________________________________________________________
6. Иҗтимагый әһәмиятле табигатьне саклау эшчәнлегенең кыскача тасвирламасы:
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
7. Табигатьне саклау чараларын тормышка ашыру территориясе:
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
8. Табигатьне саклау чараларында катнашучыларның гомуми саны: _____________

________________________________________ ___________________________

М.У. (булганда) (имза) (оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының (булганда) исеме)

_______________
(датасы)

«ЭКОлидер» еллык республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә 4 нче кушымта

Форма

**«Белем бирү оешмалары»**

конкурс төркемендә «ЭКОлидер» еллык республика конкурсында катнашучының мәгълүмат картасы

1. Номинация:

_______________________________________________________________________________

2. Белем бирү оешмасының тулы исеме: ________________________________________

_______________________________________________________________________________

3. Адресы: Татарстан Республикасы муниципаль районы: ______________________
торак пункт: _________ урам: ________________________________ йорт: ________

4. Белем бирү оешмасы җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының (булганда) исеме: ___________________________________________________________________

5. Элемтә өчен мәгълүмат:
Җаваплы затның фамилиясе, исеме, атасының (булганда) исеме:

_______________________________________________________________________________

Вазыйфасы: ____________________________________________________________
Код белән эш телефоны: _________________________________________________
Кәрәзле телефон: _______________________________________________________
E-mail: _______________________________________________________________

6. Агымдагы елның экологик белем бирү һәм мәгърифәтчелек эшчәнлегенең кыскача тасвирламасы: _______________________________________________________

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

7. Табигатьне саклау чараларын тормышка ашыру территориясе: ________________

_______________________________________________________________________________

8. Табигатьне саклау чараларында катнашучыларның гомуми саны: ______________

_______________________________________ ________________________________

М.У. (булганда) (имза) (оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының (булганда) исеме)

_______________
(датасы)

«ЭКОлидер» еллык республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә 5 нче кушымта

Форма

**«Массакүләм мәгълүмат чаралары»**

конкурс төркемендә «ЭКОлидер» еллык республика конкурсында катнашучының мәгълүмат картасы

1. Номинация: ___________________________________________________________
2. Оешманың тулы исеме/Гражданның фамилиясе, исеме, атасының (булганда) исеме (тулысынча): ______________________________________________________
3. Адресы: Татарстан Республикасы муниципаль районы: ______________________
торак пункт: ___________ урам: _____________________________________________
йорт: ________ корпус: __________ фатир: ____________________________________
4. Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының (булганда) исеме: __________________
_______________________________________________________________________________
5. Элемтә өчен мәгълүмат:
Җаваплы затның фамилиясе, исеме, атасының (булганда) исеме:
_______________________________________________________________________________
Вазыйфасы: _____________________________________________________________
Код белән эш телефоны: __________________________________________________
Кәрәзле телефон: ________________________________________________________
E-mail: _________________________________________________________________
6. Иҗтимагый әһәмиятле табигатьне саклау эшчәнлегенең кыскача тасвирламасы: (массакүләм мәгълүмат чараларында материаллар исемлеге) ___________________
_______________________________________________________________________________
7. Массакүләм мәгълүмат чараларын тарату (тапшыру) территориясе:
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________

_____________________________________________ ______________________________
М.У. (булганда) (имза) (оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының (булганда) исеме)

____________________
(датасы)

«ЭКОлидер» еллык республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә
6 нчы кушымта

Форма

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга ризалык**
**(физик затлар тарафыннан тутырыла)**

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 ел, 27 июль, ФЗ-152 нче Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, «ЭКОлидер» еллык республика конкурсын оештыручы тарафыннан түбәндәге күләмдә шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга (аларны миннән һәм/яки башка өченче затлардан алуны да кертеп) риза:

| | |
|---|---|
| Эшкәртелә торган шәхси мәгълүматлар исемлеге | (Фамилиясе, исеме, атасының (булганда) исеме, җенесе, туу көне һәм урыны, гражданлыгы, шәхесне таныклый торган документ реквизитлары (документ төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон (шул исәптән кәрәзле телефон) номеры, электрон хат адресы) |

________________________________________
(Фамилиясе, исеме, атасының (булганда) исеме, имза)

____________________
(Датасы)